Personalia

# PROFESSOR, DR.RASHID RAKHMATI ARAT

**Mustafa Oner,**
Ege University, Turkey,
Bornova, Izmir , 34100,Turkey,
mustafa.oner@ege.edu.tr.



**ARAT RASHID RAKHMATI (**Rakhmatullin Gabderashid**)** (1900-1964) – Turkologist, Doctor of Philology (1928). In 1920-1922 he lived in Harbin (China) and worked in *Jerak shariq* newspaper's editorial office. After graduating from Berlin University (1927), he taught Turk languages in Berlin and cooperated with the Berlin Academy of Sciences. Since 1933 he was a professor of Turk languages and literatures of Istanbul University. In 1951 he became a director of the Turkology Institute at Istanbul

**АРАТ РӘШИТ РӘХМӘТИ** (Рәхмәтуллин Габдерәшит) **ИСМӘТ улы** (1900-1964) – тюрколог, филология докторы (1928). 1920-1922 елларда Харбин шәһәрендә (Кытай) яши, «Ерак Шәрекъ» газетасы редакциясендә эшли. 1922 елдан Берлинда, Берлин университетын тәмамлагач (1927), шунда ук төрки телләр укыта, Берлин фәннәр академиясе белән хезмәттәшлек итә. 1933 елдан Истанбул университетының төрки телләр

**АРАТ РАШИД РАХМАТИ** (Рахматуллин Габдерашид) (1900-1964) – тюрколог, доктор филологии (1928). В 1920-1922 гг. жил в Харбине (Китай), работал в редакции газеты «Ерак Шарык». С 1922 года жил в Берлине, после окончания Берлинского университета (1927) там же преподавал тюркские языки и сотрудничал с Берлинской академией наук. С 1933 года профессор кафедры тюркских языков и литературы Стамбульского университета, с

University.

His heritage is works on Turk history, languages and literature. He is the author of the three-volume research on the ancient Turk literary masterpiece *Kotagdu belek* (*'Blessed Knowledge'*), and the founder and editor of the Islamic Encyclopedia *Islam Ansiklopedisi*.

һəм əдəбият кафедрасы профессоры. 1951 елдан Истанбул университеты каршындагы Тюркология институты директоры.

Хезмəтлəре төрки халыкларның тарихы, теллəре һəм əдəбиятларына карый. Борынгы төрки «Котадгу белек» («Игелекле белем») əдəби ядкəренə багышланган өч томлы хезмəт авторы. Ислам энциклопедиясенə («Islam Ansiklopedisi») нигез салучыларның берсе һəм мөхəррире.

1951 – директор Института тюркологии при Стамбульском университете.

Труды по истории, языкам и литературе тюркских языков. Автор трехтомного труда, посвященного исследованию древнетюркского литературного памятника «Котадгу белег» («Благодатное знание»). Один из основателей и редактор Исламской энциклопедии «Islam Ansiklopedisi».

Arat Rashid Rakhmati (G.Rakhmati, Gabderashid Rakhmati, G.Rakhmatullin), Professor of Istanbul University, a founder of the Turkish language historical-comparative linguistics school and a specialist in ancient Turkic literary monuments (Uigur-Karakhani), was born in the family of mudarris Ismaton on May, 15, 1900 in Iske Azhem village (Tatesh county), north-west of Tatarstan. After graduating from school and moving with his brother to Kazakhstan's Kiziljar (Petropavel), he studied there at the Turkish-Tatar jadidi school and the Russian grammar school.

Rashid Rakhmati was in close cooperation with the Tatar society in Manchuria's Harbin. In the days of the civil war Rashid Rakhmati, with the support of imam Akhmadibei and Khusainbei, was able to cross the border, and, at the end of 1922 after a trip taking a month and a half, he started his education in Germany. In the spring of 1923, Rashid Rakhmati started his studies in the Faculty of Philosophy at Berlin University. He was a student of prominent Turkology Professor Willy Bang Kaup, and later, on becoming his assistant, together with Annemarie von Gabain, he took an interest in old Turfan Uigur texts.

Before Arabic was widespread, Turks had used old Uigur writing and it had left a rich cultural heritage. Moreover, Uigur writing was studied in the palaces of Genghis Khan and was the very first alphabet of the Mongols. These Turk manuscripts were brought to Europe in the early 20$^{th}$ century and are treasured in German, French and British museums and archives. Rashid Rakhmati Arat was a Tatar scholar among those distinguished Turkologists who worked at the University of Berlin and studied these papers.

Rashid Rakhmati cooperated with a prominent Tatar leader who lived abroad – Gayaz Iskhaki. Rashid afende published articles in *Ynamilliyul* journal, established in Berlin.

In 1933 Rashid Rakhmati Arat accepted the position of professor at Istanbul University by special invitation of the Turkish government. So he continued the research that had been started in Berlin, but more specifically studying the heritage of the Uygur Turk languages. The result of Rashid Rakhmati's fruitful work was the publication of the *Türkische Turfan texteseriyasĕ* dedicated to Turfan Turkish texts in VI and VII volumes in 1920: *Türkische Turfan texte, VI, Das Buddhistische Sutra Säkiz Yükmäk, SPAW Phil-Hist. Kl. X. Berlin, 1934; Türkische Turfan texte, VII, SPAW Phil-Hist. Kl. XI. Berlin, 1936*.

Among the first works of the junior researcher were the ancient Turk texts on medicine and law: *Zur Heilkunde der Uiguren II: SPAW Phil. – Hist. Kl. XXII, Berlin, 1932; Uygurlar ve Uygur medeniyeti: A.Süheyl, Uygurlarda Tababet, İstanbul, 1936*. These were notable investigatons on ancient Turk terminology: *Uygurlarda ıstılahlara dair: Türkiyat Mecmuası VII – VIII, 1 (1942), 56-81*.

One of the oldest Uygur texts is *Oguz Kagan Destani*, which is held at the Paris National Library, and has great value as a source for the culture of Turks. This masterpiece, as mentioned above, had been scientifically studied and published by the linguists Rashid Rakhmati Arat and his mentor Willy Bang Kaup*: Die Legende von Oghuz Qaghan, SPAW Phil. – Hist. Kl. XXV. Berlin, 1932*. This dastan was printed in Turkish in 1936 in Istanbul. In 1970 it was included in a compilation of the 1000 old Turkish literature classics and today it is among the treasures of national culture.

R.R.Arat was strongly engaged in studies of old Turk poetry which has a thousand-year history:

*Eski Tür kŞiiri*, Ankara 1965. The scientist reviewed 35 texts among the examples of Turk poetry written under the influence of Maniheizm, Buddhism and Islam. He did not only translate them, but provided valuable philological comments. This work has not lost its uniqueness in Turkic languages studies.

The biggest ancient Turkic book *Kotagdu belek* (1069) consisting of 6645 beits, became popular in the scientific world thanks to A.Vambery and V.Radlov. This literary monument of Islamic-Turkic culture written by Balasaguni Yusuf Khass Hajib was reviewed by R.R.Arat, who based his work on manuscripts held in Egypt, Herat and Ferghana. He published the text of *Kotagdu belek* for the first time in 1947 and translated it into Turkish in 1959. After the death of Rashid Rakhmati Istanbul University scholars published the grammar index of this massive text (1979), based on the materials which had been collected by Rashid Rakhmati. Thus, the review of *Kotagdu belek* in Turkic language studies is also associated with the name of this scholar. Rashid Rakhmati Arat did the research on *Atabetul Hakayık (‘Threshold of truth’)*, written a century later than *Kotagdu belek*, and he prepared its beautiful philological review: *Atebetü’l-hakayık* (Edib Ahmed b. Mahmud Yükneki) İstanbul, 1951. This textbook has not lost its significance in Turkey even today.

Even Babur Shah’s 400-page *Baburname*, having aroused the interest of N.Ilminsky and A.S.Beveridge, and become popular around the world, gained recognition in Turkey due to R.R.Arat: *Babur, Vekayi – Tercüme I-II, Ankara, 1943-1946*. This incomparable example of the 16$^{th}$ century Turk prose, a historical encyclopedia in the Turk language, is the great source for monographs and dissertations dedicated to different areas of Turkology.

In 1939, Istanbul University began the publication of the Encyclopedia of Islam which is one of the largest sources for the humanities in Turkey. One of the most active writers of the Encyclopedia was R.R.Arat. His scientific articles on *Astırhan*; *Ayran; Balık; Baraba; Batman; Göklen; Hakim Ata; Kara-Hıtaylar; Kara-Kalpaklar; Karakol; Kara-Korum; Karşi; Kasım Hanlığı; Kaşgar; Kazakistan; Kazan; Kımız; Kıpçak; Kırgızistan; Kötel; Köy; Kutadgu Bilig; Küçüm Han; Matbuat (Kazan Türkleri, Azerbaycan, Kafkasya ve Şimalî Kafkasya Türkleri, Kırım Türkleri, Dobruca türkleri, Özbekler, Kazaklar, Türkmenler, Şarkî Türkistan, Çin Müslümanları); Oğul* hold a special place in the Encyclopedia. The encyclopedist, Professor R.R.Arat, created the textual transcription textbook: *Türkİlmî Transkripsiyon Kılavuzu, İstanbul* (1946). Today, in Turkey, nearly all historical and dialectological materials are based on his work.

By using his mentor Willy Bang Kaup’s methods, Rashid Rakhmati developed a methodology and comparative historical grammar concepts in the area of Turkology, which was rapidly growing in Europe and in the universities of Turkey. Consequently, as a result of his knowledge of many languages and the publication of his scientific works on Turkology, his status in Turk language studies made him distinguished in Turkey.

In 1924, Katanov’s library was bought upon an initiative of Mustafa Kemal Ataturk, Kazan University Professor. In 1940-1950, Prof. Dr.R.R.Arat was a director of the library, which was opened at Istanbul University’s Turkiyat Institute at that time.

Internationally recognized and full of ideas, 64-year-old Rashid Rakhmati felt that his health was getting worse. Rashid Rakhmati, the Tatar intelligentsia’s great representative, left his native city, Kazan, travelled around the world, lived some time in Europe and died in his new homeland of Turkey on November 29, 1964.

Dr.Rakhmati spent his last years at the Turkish Cultural Studies Institute in Ankara, where he left his library.

A number of articles by Dr.Gabderashid Rakhmati Arat, the Ancient Turk languages department’s Ordinarius Professor of Istanbul University, were compiled and printed by Osman F.Sartkaya: R.R.Arat, *Makaleler* – I, Ankara 1987 (1050 pages). His books *Türk Dil Kurumu* and *Türk Tarih Kurumu* are still published in academic centres. A prominent Tatar scholar, who was born in Kazan and lived his life during the times of the historical disturbances of the early 20$^{th}$ century, R.R.Arat has a place of honour in the history of the Turkish university and the world of Turkology.

**References**

1. *Çağatay S.* Reşid Rahmeti Arat (15.5.1900-29.11.1964) // TTK Belleten, XXIX 113. 1965. C.177-193. (in Turkish)
2. *Devlet N.* Türkiye’ye Katkıda Bulunan Tatar-Başkurtlar; Türkiye Cumhuriyeti Devletinin Kurutuluş ve Gelişmesine Hizmeti Geçen Türk Dünyası Aydınları Sempozyumu Bildirileri (23-26 Mayıs 1996). Kayseri, 1996. S.161-173. (in Turkish)
3. *Ercilasun A.B.* Türkiye’deki Türk Dünyası Aydınlarına Genel Bir Bakış; Türkiye Cumhuriyeti Devletinin Kurutuluş ve Gelişmesine Hizmeti

Geçen Türk Dünyası Aydınları Sempozyumu Bildirileri (23-26 Mayıs 1996). Kayseri, 1996. C.193-196. (in Turkish)
4. *Sertkaya O.F.* Ord. Prof. Dr. Reşit Rahmeti Arat (15 Mayıs 1900-29 Kasım 1964) ve Eserleri – Ölümünün 20 Yılı Dolayısıyla.Türk Dili Araştırmaları Yıllığı Belleten. 1984. C.305-313. (in Turkish)

# ПРОФЕССОР, ДОКТОР РӘШИТ РӘХМӘТИ АРАТ

**Мостафа Өнәр,**
Эгей университеты,
Төркия, 34100, Измир ш., Борнова,
mustafa.oner@ege.edu.tr.

Истанбул университеты профессоры, Төркиянең тарихи-чагыштырмалы төрек тел белеме мәктәбенә нигез салучы, борынгы төрки язмалар (Уйгыр-Карахани) өлкәсендә халыкара танылган белгеч Рәшит Рәхмәти Арат (Г.Рахматы, Габдуррәшид Рәхмәти, Г.Рахматуллин) 1900 елның 15 нче маенда Татарстанның төньяк-көнбатышында урнашкан Иске Әҗем авылында (Тәтеш өязе) мөдәррис Исмәт гаиләсендә дөньяга килә. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, абыйсы белән Казахстанның Кызылъяр (Петропавел) шәһәренә китә, анда төрек-татар җәдит мәктәбендә һәм рус гимназиясендә белем ала.

Маньчжуриянең Харбин шәһәрендәге Татар җәмгыяте белән аралашып яшәгән Рәшит Рәхмәти, имам Ахмәди бәй һәм Хөсәен Абдүш бәй ярдәме белән, гражданнар сугышы чорында чит илгә чыгып, авыр шартлардагы ай ярымлык сәяхәтеннән соң, 1922 ел ахырында Германиягә укырга китә. 1923 елның язында Берлин университетының фәлсәфә факультетына укырга кергән Рәшит Рәхмәти мәшһүр тюрколог профессор Вилли Банг-Каупның – укучысы, соңрак аның ассистенты буларак, Аннемари фон Габайн белән бергә, Турфаннан китерелгән борынгы уйгыр язмалары белән кызыксына башлый.

Төркиләр арасында гарәп язуы таралганчы файдаланылган һәм бай мәдәни мираска ия борынгы уйгыр язуы Чыңгыз хан дәүләте сарайларында өйрәнелгән һәм монгол милли теленең беренче әлифбасына әверелгән була. XX йөз башында Европа илләренә китерелгән әлеге төрки язмалар Германия, Франция, Британия музейлары һәм архивларында саклана. Берлин университетының дөньякүләм танылган тюркологлары арасында бу язмаларны өйрәнүче татар галиме Рәшит Рәхмәти Арат та була.

Рәшит Рәхмәти чит илләрдәге татарларның мәшһүр юлбашчысы Гаяз Исхакый белән аралашып яши, Берлинда 1930 елда чыга башлаган «Яңа милли юл» журналына да мәкаләләр яза.

1933 елда, Төркия җөмһүриятенең махсус чакыруы буенча, Истанбул университетында профессор вазифасына керешкәч, Рәшит Рәхмәти Арат Берлинда башлаган гыйльми эшчәнлеген, ягъни борынгы уйгыр язулы төрки тел мирасын өйрәнүен дәвам итә. Берлинда 1920 елларда төзелгән төрекчә Турфан текстларының (Türkische Turfantexte seriyasĕ) VI һәм VII томнары Рәшит Рәхмәти хезмәтенең нәтиҗәсе буларак басылып чыга: Türkische Turfantexte, VI, Das Buddhistische Sutra Säkiz Yükmäk, SPAW Phil-Hist. Kl. X. Berlin, 1934; Türkische Turfantexte, VII, SPAW Phil-Hist. Kl. XI. Berlin, 1936.

Яшь галимнең беренче тикшеренүләре арасында борынгы төркиләрнең медицина һәм хокук документлары да була: Zur Heilkunde der Uiguren II: SPAW Phil. - Hist. Kl. XXII, Berlin, 1932; Uygurlar ve Uygur medeniyeti: A.Süheyl, Uygurlarda Tababet, İstanbul, 1936. Рәшит Рәхмәти Аратның борынгы төрки терминнар турында да җитди хезмәтләре бар: Uygurlarda ıstılahlara dair: Türkiyat Mecmuası VII - VIII, 1 (1942), 56-81.

Борынгы уйгыр язмаларының берсе – Париж Милли китапханәсендә сакланган Угыз Каган дастаны (Oguz Kagan Destani) – төрки мәдәният өчен бик зур әһәмияткә ия чыганак буларак кабул ителә. Бу ядкәрнең дә гыйльми филологик басмасын Рәшит Рәхмәти Арат остазы Вилли Банг-Кауп белән бергә башкарып чыга: Die Legende von Oghuz Qaghan, SPAW Phil.-Hist. Kl. XXV. Berlin, 1932. Бу дастанның 1936 елда Истанбулда төрекчәсе нәшер ителә һәм, 1970 елда төрек классикасының мең

үрнәге арасында да басылып, милли мәдәни хәзинәгә әверелә.

Р.Р.Арат мең еллык тарихы булган борынгы төрки шигърият белән турыдан-туры кызыксына: Eski Türk Şiiri, Ankara 1965. Галим бу китабына манихеизм, буддизм һәм ислам тәэсирендә язылган төрки поэзиянең беренче үрнәкләре арасыннан 35 текстны эшкәртеп, тәрҗемә итеп кенә калмый, кыйммәтле филологик искәрмәләр дә бирә. Бу хезмәт бүген дә тюркологиядә уникальлеген югалтмый.

Борынгы төрки телнең 6645 бәеттән торган иң зур китабы «Котадгу белек»не (1069) А.Вамбери һәм В.Радловлар фәнни әйләнешкә кертә. Ислам-төрки мәдәниятенең Баласагуни Йосыф Хас Хаҗиб тарафыннан язылган бу ядкәренең, Мисыр, Херат һәм Фирганәдә сакланган кульъязмаларга таянып, фәнни басмасын эшләгән галим дә Р.Р.Арат була. Ул 1947 елда Әнкарада «Котадгу белек»нең текстын тәүге тапкыр бастыра һәм 1959 елда аның төрекчәгә тәрҗемәсен дә эшли. Истанбул университеты галимнәре, Рәшит Рәхмәтинең вафатыннан соң, аннан калган материалга таянып, бу зур текстның грамматик индексын нәшер итәләр (1979). Шулай итеп, «Котадгу белек» тә тюркология фәнендә бу галимнең исеме белән бәйләнә. Әдип Әхмәт Йүгнәкинең «Котадгу белег»еннән бер гасыр соңрак язылган «Һибәтел-хәкаикъ» («Хакыйкатьләр бусагасы») әсәрен Рәшит Рәхмәти Арат текстология һәм филология өлкәсендә матур бер үрнәк итеп әзерли: Atebetü'l-hakayık (Edib Ahmed b. Mahmud Yükneki) İstanbul, 1951. Бу хезмәт, гыйльми кулланма буларак, Төркиядә бүген дә актуальлеген югалтмый.

Бабур Шахның Н.Ильминский, А.С.Бевериджларда, гомумән, бөтендөнья халыкларында зур кызыксыну уяткан 400 биттән артык зур күләмле истәлеге «Бабурнамә» дә Төркиядә Р.Р.Арат тәрҗемәсендә танылa: Babur, Vekayi - Tercüme I-II, Ankara, 1943-1946. Әлеге ядкәр төрки дөнья әдәбиятында, XVI йөзнең тиңдәшсез проза үрнәге, төрки телдә язылган тарих энциклопедиясе буларак, тюркологиянең төрле өлкәләрендә эшләнгән диссертацияләргә һәм монографияләргә чыганак ролен үти.

1939 елда, Истанбул университеты каршында, Төркиядә гуманитар фәннәрнең иң зур чыганагы булган Ислам энциклопедиясе чыга башлагач, аның актив авторларының берсе, шулай ук Р.Р.Арат була. Ул язган *Astırhan*; *Ayran; Balık; Baraba; Batman; Göklen; Hakim Ata; Kara-Hıtaylar; Kara-Kalpaklar; Karakol; Kara-Korum; Karşi; Kasım Hanlığı; Kaşgar; Kazakistan; Kazan; Kımız; Kıpçak; Kırgızistan; Kötel; Köy; Kutadgu Bilig; Küçüm Han; Matbuat (Kazan Türkleri, Azerbaycan, Kafkasya ve Şimalî Kafkasya Türkleri, Kırım Türkleri, Dobruca türkleri, Özbekler, Kazaklar, Türkmenler, Şarkî Türkistan, Çin Müslümanları); Oğul* кебек гыйльми мәкаләләре энциклопедиядә әһәмиятле урын алып тора. Энциклопедист галим, профессор Р.Р.Арат, текстологик транскрипция кулланмасын да язып калдырган белгеч: Türk İlmî Transkripsiyon Kılavuzu, İstanbul, 1946. Бүгенге көндә дә Төркиядә бөтен тарихи текстлар һәм диалектология материаллары ул бастырган хезмәт нигезендә нәшер ителә.

Рәшит Рәхмәти – үз укытучысы В.Банг-Каупның ысуллары нигезендә Европада үсә башлаган тюркология фәненең методологиясен, чагыштырмалы-тарихи грамматика юнәлешен Төркия университетларында фәнни әйләнешкә керткән галим. Ә бу исә, үз чиратында авторның күп телләрне белүе нәтиҗәсендә язылган гыйльми хезмәтләре белән төрки дөньяда һәм тюркология фәнендә ирешкән дәрәҗәсенең Төркиядә танылуына китерә.

1924 елда Мостафа Кәмал Ататөрк инициативасы белән Казан университеты профессоры Н.Ф.Катанов китапханәсе сатып алына. Истанбул университетының Төркият институтында шул нигездә ачылган китапханәдә 1940-1950 елларда профессор, доктор Р.Р.Арат директор вазифасын башкара.

Халыкара танылып, яңа гыйльми эзләнүләр белән кайнаган 64 яшьлек Рәшит Рәхмәтинең сәламәтлеге какшый башлый. Шулай итеп, татар зыялыларының бер вәкиле Рәшит Рәхмәти, туган ягы Казаннан китеп, дөнья гизгәннән соң, Европада беркадәр яшәп алгач, үзенең ватаны итеп кабул иткән Төркиядә 1964 елның 29 ноябрендә вафат була.

Мәрхүм галимнең соңгы еллар эшчәнлеге бер төркем гуманитар фәннәр галимнәре тарафыннан Әнкарада ачылган Төрки мәдәни тикшеренүләр институтында уза, шәхси китапханәсе дә үз васыяте белән шунда калдырыла.

Истанбул университетының Борынгы төрки тел кафедрасы ординариус профессоры, доктор Абдеррәшит Рәхмәти Арат мәкаләләренең бер өлеше Осман Ф.Сәрткайа тарафыннан җыелып тупланып нәшер ителә: R.R.Arat, Makaleler- I, Ankara 1987 (1050 бит). Китаплары Төрек тел

корумы (Türk Dil Kurumu), Төрек тарихы корумы (Türk Tarih Kurumu) кебек академик үзәкләрдә әле дә басыла тора. Татар халкының күренекле вәкиле, XX йөз башы тарихи-сәяси давыллар чорында туып үскән Р.Р.Арат мәңгелек хезмәтләре белән Төркия җөмһүрияте университеты тарихында һәм тюркология дөньясында шәрәфле урынны алып тора.

**Әдәбият**


1. *Çağatay S.* Reşid Rahmeti Arat (15.5.1900 - 29.11.1964) // TTK Belleten, XXIX 113. 1965. C.177-193.
2. *Devlet N.* Türkiye'ye Katkıda Bulunan Tatar-Başkurtlar; Türkiye Cumhuriyeti Devletinin Kurutuluş ve Gelişmesine Hizmeti Geçen Türk Dünyası Aydınları Sempozyumu Bildirileri (23-26 Mayıs 1996). Kayseri, 1996. C.161-173.
3. *Ercilasun A.B.* Türkiye'deki Türk Dünyası Aydınlarına Genel Bir Bakış; Türkiye Cumhuriyeti Devletinin Kurutuluş ve Gelişmesine Hizmeti Geçen Türk Dünyası Aydınları Sempozyumu Bildirileri (23-26 Mayıs 1996). Kayseri, 1996. C.193-196.
4. *Sertkaya O.F.* Ord. Prof. Dr. Reşit Rahmeti Arat (15 Mayıs 1900-29 Kasım 1964) ve Eserleri – Ölümünün 20 Yılı Dolayısıyla.Türk Dili Araştırmaları Yıllığı Belleten. 1984. C.305-313.